Дүртенче чакырылыш Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советының кырык икенче утырышы

Татарстан Республикасы
Питрәч муниципаль районы Советы
КАРАРЫ

22 май, 2024 ел № 330

Питрәч муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге эшне оештыру турында

Питрәч муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе урынбасары А. Д. Сабитовның Питрәч муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге эшне оештыру турындагы мәгълүматын тыңлап **Татарстан Республикасы Питрәч муниципаль районы Советы карар кабул итте:**

1. Питрәч муниципаль районы территориясендә каты коммуналь калдыклар белән эш итү өлкәсендәге эшне оештыру турындагы мәгълүматны игътибарга алырга.

2. Питрәч муниципаль районы башкарма комитетына:

2.1. авыл җирлеге башлыклары белән каты коммуналь калдыклар җыю мәйданчыкларын урнаштыруның өстәмә урыннарын билгеләргә.

2.2. районның финанс-бюджет палатасы белән каты коммуналь калдыклар җыю мәйданчыклары төзү һәм контейнерлар сатып алу өчен финанслау чыганагын билгеләргә.

3. Авыл җирлеге башлыкларына Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре палатасы белән берлектә кадастр эшләре һәм авыл җирлекләренең муниципаль милек хокукын теркәү үткәрергә.

4. «Торак-коммуналь хуҗалык предприятиесе «Идарәче компаниясе» ҖЧҖнең каты коммуналь калдыклар белән эш итү буенча төбәк операторына Питрәч муниципаль районында каты коммуналь калдыкларны чыгару эшен көчәйтергә, чыгару графигының өзелүенә юл куймаска киңәш итәргә.

5. Әлеге карарны Питрәч муниципаль районы рәсми сайтында (www.pestreci.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

6. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Питрәч муниципаль районы Советының экология, табигатьтән файдалану, төзекләндерү һәм аграр мәсьәләләр буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Питрәч муниципаль районы
башлыгы урынбасары В.А. Игнатьева